ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.05.2020 ел Баулы шәһәре № 120

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының "Баулы муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында"гы 2020 елның 20 маендагы №113 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының "Баулы муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында"гы 2020 елның 20 маендагы №113 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче пунктта 1 абзацта «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Спортны һәм туризмны үстерү бүлеге» муниципаль бюджет учреждениесенең ведомство буйсынуындагы учреждениеләре» сүзләрен “муниципаль физкультура-спорт оешмалары,» сүзләренә алмаштырырга;

4нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров